СОВЕТ МАЛОМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛ РАЙОНЫ
КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 30 нчы сентябере Кече Мәми авылы № 25

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Кече Мәми авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Уставының 22статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2019 елның 22 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Кече Мәми авылы, Үзәк урамы, 2а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 24 октябрендә 14 сәгать 00 минутка Кече Мәми авылы,Үзәк урамы, 2а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең Кече Мәми авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:

- материаллар сатып алып һәйкәлне төзекләндерү;

б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- коены ремонтлау, төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кече Мәми авыл җирлеге башлыгы Е.Н. Алексеева